**Шәһәр күләмендә Татарстан һәм татар халкы тарихы фәненнән**
**үткәрелә торган олимпиаданың**
**мәктәп этабы сораулары**
**2017-18 уку елы**
**8 нче сыйныф**

Биремнәрне үтәү өчен 2 сәгать вакыт бирелә.
Иң югары балл - 33балл.

**1 бүлек. Тәкъдим ителгән җаваплар арасыннан дөресен сайлап алыгыз. 5 биремгә 1әр балл. (Иң югары – 5 балл)**

**1. Каюм Насыйри тарафыннан нәшер ителгән беренче татар календаре кайчан чыга башлый ?**
А) 1876 ел, 3 октябрь Б) 1883 ел, 2 гыйнвар В) 1871 ел, 6 гыйнвар
Җавап: ______________________________

**2. Кадимчелек ул:**
А) XIX гасыр ахырында татар җәмгыятендә барлыкка килгән консерватив хәрәкәт;
Б) татар иҗтимагый тормышының төрле өлкәләрен яңартуга юнәлдерелгән иҗтимагый-сәяси хәрәкәт;
В) христиан булмаганнар арасында дини пропаганда алып бару
Җавап: ______________________________

**3. Бизнә восстаниесе кайчан була?**
А) 1871 елның 6 гыйнварында
Б) 1861 елның 12 апрелендә
В) 1861 елның 16 апрелендә
Җавап: ______________________________

**4. Бодуэн де Куртене (1845-1929):**
А) математик
Б) тел белгече, Казан лингвистика мәктәбенә нигез салучы
В) шагыйрь
Җавап: ______________________________

**5. Казан университеты кайчан ачыла?**
А) 1804 Б) 1806 В) 1817
Җавап: ______________________________

**2 бүлек. Туры китерүгә нигезләнгән биремнәр.**
**6. Вакыйгаларны һәм даталарны туры китерегез: (Һәрбер дөрес җавап өчен 1 б., иң югары – 4 б.)**

| Вакыйга | Дата |
|---|---|
| 1) Куртина панихидасы | А) 1891-1893 еллар |
| 2) Вәисиләр хәрәкәте башлана | Б) 1861 ел, 16 апрель |
| 3) Мәскәү-Казан тимер юлы төзелә | В) 1882 ел |
| 4) «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе ачыла | Г) 1862 ел |

Җавап:

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | |

**7. Шәхесләрне һәм аларның яшәү елларын туры китерегез: (Һәрбер дөрес җавап өчен 1 б., иң югары – 4 б.)**

| **Шәхес** | **Яшәү еллары** |
|---|---|
| 1) Галимҗан Баруди | А) 1776-1846 |
| 2) Карл Фукс | Б) 1828-1866 |
| 3) Хөсәен Фәезханов | В) 1825-1902 |
| 4) Каюм Насыйри | Г) 1857-1921 |

Җавап:

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | |

**8. Галимнәрнең исемнәрен аларның фәнни казанышлары белән туры китерегез: (Һәрбер дөрес җавап өчен 1 б., иң югары – 4 б.)**

| **Автор** | **Әсәр** |
|---|---|
| 1) М.А.Ковальский | А) органик кушылмаларның химик төзелеше теориясен эшли |
| 2) .М.Бутлеров | Б) Евклидча булмаган геометрияне төзүче |
| 3) Н.И.Лобачевский | В) Казан университетының медицина факультетында күз клиникасын оештыра |
| 4) Е.В.Адамюк | Г) Кояшның хәрәкәтен өйрәнүнең яңа ысулын эшли, башка галимнәрдән ярты гасыр элегрәк Галактиканың әйләнүе турындагы идеяне әйтә |

Җавап:

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | |

**9. Исемлектә артык булган шәхесне билгеләгез: (1 б.)**

1) Н.Н. Зинин 2) А.М. Бутлеров 3) И.А. Бодуэн де Куртенэ

Җавап: ______________________________

**10. Исемлектә артык булган шәхесне билгеләгез: (1 б.)**

1) Алафузов Иван Иванович
2) Ушков Петр Капитович
3) Рыбушкин Михаил Самсонович
4) Үтәмешев Мөхәммәдгариф Ибраһим углы
5) Юнысов Ибраһим Гобәйдулла углы

Җавап: ______________________

**3 бүлек. Рәсемнәр белән эшләүгә нигезләнгән бирем.**

**11. Фоторәсемне игътибар белән карагыз һәм сорауларга җавап бирегез. (Иң югары 5 б.)**



**Фоторәсемдә кем сурәтләнгән? (1 б.)**

______________________________________________

**Фоторәсем кайсы гасырга карый? (1 б.)**

______________________________________________

______________________________________________

**Фоторәсемдә сурәтләнгән шәхеснең тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында белгәннәрегезне языгыз. (Һәрбер биографик факт өчен 1 б., иң югары – 3 б.)**

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

**4 бүлек. Чыганак текстлары белән эшләүгә нигезләнгән биремнәр.**

**12. Текстны игътибар белән укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез:**

*Театр тора-бара мине тагын да күбрәк тарта башлады, һәм мин җыр белән эшләп тапкан акчаларымны ешрак яшереп калдыра башладым. Моның яхшы гадәт булмавын аңласам да, театрга йөрмәү минем өчен мөмкин булмаган хәл иде...*

*Берзаман опера килеп төште, һәм билет бәяләре 30 тиенгә кадәр күтәрелде. Опера мине шулкадәр сокландырды. Җырчы буларак мин, әлбәттә, кешеләрнең җырлавына һәм аңлашылып бетмәгән сүзләр белән җырлавына сокланмадым, мин үзем дә туйларда: "Яви ми зрак!"– дип һәм шуның кебегрәк җырлар суза идем; мине кешеләрнең Казан йортлары һәм урамнарында гадәтләнгәнчә сөйләшмәве, ә бөтен нәрсә турында да җырлап сөйләшүгә көйләнгән тормышта яшәве хәйран калдырды. Бу җырлап яшәү мине шаккатырмый кала алмады. Гаҗәеп сокларгыч киемнәр кигән гаҗәеп кешеләр сорау биргәндә дә, җавап кайтарганда да җырлыйлар; уйлаганда, ачуланганда, үлгәндә дә җырлыйлар; утырып та, басып та, хор белән, икәүләп яки башкача да җырлыйлар!..*

**Текстта сүз кем исеменнән бара? (1 б.).**

______________________________________________________________________________

**Әлеге шәхеснең тормыш юлы Казан шәһәре белән ничек бәйләнгән була? (Һәрбер биографик факт өчен 1 б., иң югары – 3 б.)**

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

**13. Текстны игътибар белән укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез:**

*«Мин үлемнән курыкмыйм. Бу буш сүз түгел. Без үлемгә җирәнеп карыйбыз дип әйтәбез икән, бу чыннан да шулай бит. Куркыныч хәлләргә очраган чакларда, мин үлем турында котым очып уйлап утыруымны белмим. Бөек патриотизм хисе, үзеңнең җәмәгать функцияңне тулысынча аңлау кешене шәхси курку хисләреннән өстен күтәрә. Үлем турында башка берәр уй килеп төшә икән, болай фикер йөртәсең: үлемнән соң да яшәү бар бит әле. ...Үлгәннән соң халык күңелендә, халык аңында яши торган тормыш бар. Әгәр дә мин исән чакта нинди дә булса әһәмиятле, үлми торган эш эшләп калдыра алсам, моның белән мин икенче кабат яшәргә – үлгәннән соң да яшәргә хокук алам. Чөнки минем турында сөйләячәкләр, язачаклар, ихтимал, рәсемнәремне дә басып чыгарырлар. Әгәр мин шуңа ирешә алам икән, ни дип үлемнән куркырга? ДӨНЬЯДА ШУНДЫЙ ИТЕП ЯШӘРГӘ КИРӘК, ҮЛГӘННӘН СОҢ ДА ҮЛМӘСЛЕК БУЛСЫН – ЯШӘҮНЕҢ БӨТЕН МАКСАТЫ ШУНДА ТҮГЕЛМЕНИ?»*

*12 гыйнвар, 1942 ел.*

**Бу сүзләрне язып калдырган татар шагыйренең исемен күрсәтегез. (1 б.)**

______________________________________________________________

**Әлеге шагыйрь кайда, кайчан һәм кем тарафыннан үтерелә? (1 б.)**

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________

**Шагыйрьнең халык күңелендә исемен мәңгеләштергән берничә шигырен атагыз. (Һәрбер шигыре өчен 1 б., иң югары – 3 б.)**

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

________________________________

**УҢЫШЛАР ТЕЛИБЕЗ!**